**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 25 апрелендәге 1285 номерлы карары**

**«Россия – Ислам дөньясы: KazanForum» 2025 халыкара икътисади форумын һәм Казан шәһәрендә «Киләчәкне формалаштыру» халыкара мәгариф министрлары форумын әзерләү һәм уздыру чорында транспорт чараларын куеп торуны һәм аларның хәрәкәтен вакытлыча чикләү турында**

«Россия – Ислам дөньясы: KazanForum» 2025 халыкара икътисади форумын һәм Казан шәһәрендә «Киләчәкне формалаштыру» халыкара мәгариф министрлары форумын әзерләү һәм уздыру максатыннан, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 маендагы 372 номерлы «Төбәк яки муниципальара, җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү яисә туктату тәртибен раслау турында»гы карары нигезендә:

1. **Карар бирәм**:

1.1. «Спорт һәм социаль проектлар дирекциясе» автоном коммерцияле булмаган оешма билгеләгән форма буенча махсус рөхсәт кәгазьләре белән җиһазландырылган транспорт чараларыннан кала (кирәк булганда), Һ.Такташ урамының Спартак урамыннан М.Сәлимҗанов урамына кадәрге өлешендә 2025 елның 15 маенда 00:00 сәгатьтән 2025 елның 17 маенда 00:00 сәгатькә кадәр, 2025 елның 10 июнендә 00:00 сәгатьтән 2025 елның 14 июнендә 00:00 сәгатькә кадәр транспорт чараларын куеп торуга һәм аларның хәрәкәтенә чикләүләр кертергә;

1.2. «Спорт һәм социаль проектлар дирекциясе» автоном коммерцияле булмаган оешма билгеләгән форма буенча махсус рөхсәт кәгазьләре белән җиһазландырылган транспорт чараларыннан тыш, «Ак Барс Арена» стадионы тирәсендәге автомобиль юлы участогының Чистай урамыннан «Ак Барс Арена» стадионының VSA-1 керү төркеменә кадәрге өлешендә 2025 елның 12 маенда

00:00 сәгатьтән алып 2025 елның 19 маенда 00:00 сәгатькә кадәр транспорт чараларының ике яклы хәрәкәтен оештырырга;

1.3. Казан шәһәре Башкарма комитетының Транспорт комитетына (А.В.Сидоров):

1.3.1. вакытлыча юл билгеләрен урнаштыру һәм гамәлдәге юл билгеләрен каплау чараларын оештырырга;

1.3.2. транспорт чараларын куюны һәм аларның хәрәкәтен вакытлыча чикләү турындагы мәгълүматны Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының Интернет челтәрендә Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасы рәсми порталы» дәүләт мәгълүмат системасы составына керә торган рәсми сайтында урнаштырырга;

1.4. Казан шәһәре Башкарма комитетының Тышкы төзекләндерү комитетына (И.И.Сәлахетдинов) Казан шәһәре Башкарма комитетының Вахитов һәм Идел буе районнары администрациясе (А.И.Салихов), Авиатөзелеш һәм Яңа Савин районнары администрациясе (Р.Х.Шәмсетдинов) белән берлектә юлларны йөк техникасы яки таранга каршы блоклар белән ябу эшен оештырырга;

1.5. әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга һәм Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

2. **Тәкъдим итәм**:

2.1. Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсенә (Н.Д.Закиров) әлеге карар нигезендә Казан шәһәре урам-юл челтәренең югарыда күрсәтелгән участокларында юл хәрәкәте иминлеген саклауны һәм оештыру-көйләү гамәлләрен башкаруны контрольдә тотуны тәэмин итәргә;

2.2. Казан шәһәре Думасы аппаратының мәгълүмат-аналитика идарәсенә (В.А.Казанцев) урам-юл челтәренең күрсәтелгән участогында транспорт чараларын куеп торуны һәм аларның хәрәкәтен вакытлыча чикләүне кертү турында массакүләм мәгълүмат чаралары аша хәбәр итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка **йөкләргә**.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**